ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР СУКСУЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423736, Татар Суксуы авылы, Гагарин урамы, 1Б йорт. Тел.3-44-60.

СОВЕТ ТАТАРСКО-СУКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423736,село Татарские Суксы, улица Гагарина, д.1Б, тел 3-44-60.

**КАРАР** **Решение**
**17 .09.2019** **№27**

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

"Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" " 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль Законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Татар Суксуы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 12, 75 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге башкарма комитетының «Референдум үткәрү инициативасы турында» гы 2019 елның 16 сентябрендә кабул ителгән 16 санлы карары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 сентябрендә кабул ителгән 20 санлы «Референдум үткәрү инициативасы турында " карары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турында Нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге Советы **карар кылды**:

1. 2019 елның 17 ноябренә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2020 елда үзара салымның бер тапкыр түләвен кертү белән килешәсезме 500 (биш йөз) сум, Татар Суксуы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан кала, алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү турында:

Йорт яны территорияләрен төзекләндерү:

-хуҗасыз территорияләрне карау,

Автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-авыл эчендәге юлларны, урам юлларын гравий тушэмэсе белэн тозеклэндеру хэм грейдерлау,

Ритуаль хезмэтлэрне оештыру, күмү урыннарын карап тоту:

-авыл жирлеге зират коймаларын, куму очен кирэк булган жихазларны саклау урыннарын тозеклэндеру, зиратларны теркэу,

Авыл жирлеге территориясен тозэту- тозеклэндеру эшлэре буенча:

-урамнарны яктырту, урам утларын ремонтлау;

-обелискларны, хэйкэллэрне ремонтлау

Халыкнын ялын оештыру буенча:

-Сабантуй мэйданчыгын тозеклэндеру,

- балалар уеннары мэйданчыгы булдыру.

- урам исемнэре, йорт номерлары кую, белдеру такталыры булдыру;

- дамбаларда декларация алды тикшеруе уткэру;

Су чыганаклын карау, скважиналарны койма белэн эйлэндереп алу, лицензиялэу

"ӘЙЕ" "ЮК"

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә: ТР, Актаныш муниципаль районы, Татар Суксуы авылы, Гагарин ур. 1Б йорт; ТР, Актаныш муниципаль районы, Мари-Суксуы авылы, И.Минлибаев урамы, 29 йорт, ТР, Актаныш муниципаль районы, Яна Кормаш авылы, Үзәк урамы, 41А йорт; ТР, Актаныш муниципаль районы һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Хамматуллина